Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Смәел авыл җирлегенең Смәел торак пунктында ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

№2

5 декабрь 2019 ел.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Смәел авыл җирлегенең Смәел торак пунктында халык җыены карар бирә:

1. Смәел авыл җирлегенең Смәел авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

95% күләмендә балачактан инвалидларга, балигъ булмаган балалар тәрбияләүче тулы булмаган гаиләләргә, ялгыз өлкән яшьтәге пенсионерларга, Россия армиясендәге гражданнарга, 50% күләмендә көндезге бүлектә укучы студентларга ташламалар ясарга.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару өчен юлларга:

- Бауман урамындагы зират коймасын ремонтлау;
- Бауман урамындагы һәйкәлне ремонтлау, коймасын ясау;
- Бауман урамында 2 янгын гидранты урнаштыру ;

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Смәел авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, baltasi.tatarstan.ru Балтач муниципаль районының рәсми сайтында, http:// pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына керту өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет Рәисе Р. Г. Йосыпов